**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2016 елның 3 октябре №56

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 10, 83 статьялары нигезендә, Күгәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендәге 9 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Күгәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 55 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында " карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2017 елда Күгәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу;

2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Күгәй авылы,Тынычлык урамы,16 нчы йорт (администрациясе бинасы) һәм Тауиле авылы,Үзәк урамы,22 нче йорт (авыл клубы бинасы) адреслары буенча халыкка хәбәр итәргә.

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф. Х. Хисаметдинова**